РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

22.07.2026 № 245/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының комплекслы программасын раслау турында» 2024 елның 13 декабрендәге 378/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук 2025 - 2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Буа муниципаль районы комплексլы программасының программа чаралары исемлегенә үзгәрешләр кертү кирәклегенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «2025-2028 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының комплекслы программасын раслау турында» 2024 елның 13 декабрендәге 378/БК/к карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 нче бурычка 1 нче кушымта нигезендә редакциядә 1.16, 1.17, 1.18, 1.19 пунктлары өстәргә.

1.2. 2 нче бурычка 2 нче кушымта нигезендә 2.6, 2.7 пунктлары өстәргә.

1.3. «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль законны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә 3 нче кушымта нигезендә түбәндәге эчтәлекле гамәлгә ашыру турында» 5 нче бурыч өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырылырга тиеш (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Р.Шакирҗанов

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының
_ _ _ номерлы карарына кушымта

1 нче кушымта

**1бурыч: Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсе кимү**

| Төп чараларның исеме | Бшкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның әһәмияте | Җирле бюджет исәбеннән финанслау |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 ел | 2026 ел |
| 1.16 Социаль мошенниклык өлкәсендәге хокук бозуларга, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләренә бәйле хокук бозуларга (хокук бозулар кылына торган гражданнарның төрләре, ысуллары һәм категорияләре буенча сан ягыннан)анализ ясарга | БМР БК, эчке эшләр бүлеге | 2026- 2028 еллар | | – | – |
| 1.17 Социаль мошенниклык кылуның яңа төрләре һәм ысуллары, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә гражданнарга мәгълүмат бирүче затларны укытуны уздырырга | эчке эшләр бүлеге | 2026- 2028 еллар | | – | – |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.18 Гражданнарга социаль мошенниклык кылуның яңа төрләре һәм ысуллары турында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә мәгълүмат бирү:<br>- мәгълүмат материалларын тарату;<br>- әңгәмәләр, лекцияләр, «түгәрәк өстәлләр» үткәрү һ. б. | БМР БК, эчке эшләр бүлеге | 2026- 2028 еллар | | – | – |
| 1.19 РФ Дәүләт хезмәтләре сайтында Физик затлар кредитларына үз-үзен тыюдан файдалану мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат бирү буенча эш кертергә | БМР БК, эчке эшләр бүлеге «Знамя» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2026- 2028 еллар | | – | – |

2 нче кушымта

**2 бурыч: Хөкем ителгәннәрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру**

| Төп чараларның исеме | Бшкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның әһәмияте | Җирле бюджет исәбеннән финанслау |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 ел | 2026 ел |
| 2.6 Ярдәм күрсәтергә: үзенә карата пробация кулланыла торган затның үз хокукларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар алуына; гомуми белем, урта һөнәри белем алуда, һөнәри белем алуда, квалификация күтәрүдә; эшсезлек буенча пособие алуда; РФ законнары нигезендә социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен алуда; медицина ярдәме алуда; пенсия тәэминаты алуда; социаль хезмәтләр алуда; яшәү урыны булмаганнарга вакытлыча тору урыны бирүдә һәм/яисә туклану бирүдә; башка ярдәм алуда. | халыкны эш белән тәэмин итү бүлеге, социаль яклау бүлеге, авыл җирлекләре, Җәзаларны үтәү Федераль хезмәте идарәсе(килешү буенча), РҮХ(килешү буенча), пенсия фонды, мәгариф бүлегег һәм профилактик алауның | 2026- 2028 еллар | | – | – |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | башка субъектлары (килешү буенча) | | | | |
| 2.7 Социаль элемтәләрне торгызуга, булдыруга һәм ныгытуга, социаль һәм Хокукый мәсьәләләр буенча консультацияләр бирүгә, юридик һәм психологик ярдәм күрсәтүгә ярдәм итәргә. | халыкны эш белән тәэмин итү бүлеге, социаль яклау идарәсе, Җәзаларны үтәү Федераль хезмәте идарәсе(килешү буенча) | 2026- 2028 еллар | | – | – |

3 нче кушымта

**5 бурыч: Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль законны гамәлгә ашыру**

| Төп чараларның исеме | Бшкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның әһәмияте | Җирле бюджет исәбеннән финанслау |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 ел | 2026 ел |
| 5.1 Социаль элемтәләрне торгызуда, булдыруда һәм ныгытуда ярдәм күрсәтү | БМР БК юристы, Җәзаларны үтәү Федераль хезмәте идарәсе белгече, социаль хезмәткәр, | 2026- 2028 еллар | **31** | **27**<br>– | – |
| 5.2 Социаль мәсьәләләр һәм Хокукый мәсьәләләр буенча консультацияләр бирү, юридик, психологик, социаль һәм медицина ярдәме күрсәтү | БМР БК юристы, Җәзаларны үтәү Федераль хезмәте идарәсе белгече,, социаль хезмәткәр, Буа РҮХ | 2026- 2028 еллар | | **–** | **–** |
| 5.3 Ярдәм күрсәтү: | | | | **–** | **–** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| - документларны алуда (яңартуда, алыштыруда);<br><br>- эшкә урнашуда;<br>- белем алуда, һөнәри белем алуда, квалификация күтәрүдә;<br>- социаль контракт, пособие нигезендә дәүләт социаль ярдәмен алуда;<br>- пенсия тәэминаты алу;<br>- яшәү урыны булмаган кешеләргә вакытлыча тору урыны һәм/ яки туклану урыны бирү. | БМР БК, эчке эшләр бүлеге, Җәзаларны үтәү Федераль хезмәте идарәсе белгече, социаль хезмәткәр, халыкны эш белән тәэмин итү бүлеге, Пенсия фонды. | 2026- 2028 еллар | | | |